ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

18 06 2021 г. № 192

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының аерым муниципаль хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының аерым муниципаль хокукый актларына кертелә торган кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
торак сәясәте бүлеге җитәкчесе — Е.С. Митрошенкова

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044681

Татарстан Республикасы
Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының
2021 елның 18 нче июнь
192 нче номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының аерым муниципаль хокукый актларына кертелә торган үзгәрешләр

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының түбәндәге муниципаль хокукый актларына үзгәрешләр кертергә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2014 елның 26 мартында кабул ителгән 45 номерлы карары белән расланган биналар һәм корылмалар төзү өчен җир эшләре башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2020 елның 28 сентябрендә кабул ителгән 227 номерлы карары белән расланган каты коммуналь калдыклар туплау урынын (мәйданын) төзүне килештерү һәм каты коммуналь калдыклар туплау урыны (мәйданы) турында белешмәләрне каты коммуналь калдыклар туплау урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2018 елның 15 гыйнварында кабул ителгән 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2016 елның 15 мартында кабул ителгән 74 номерлы карары белән расланган күчемсез милек объектларына адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

1.1. 1 бүлекне түбәндәге эчтәлекле текст белән тулыландырырга: «Мәгълүмати технологияләрдән файдаланып, мондый хезмәт күрсәтү процедураларын автоматлаштыруны тәэмин итүче муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының машина укый ала торган тасвирламасы мәгълүмат технологияләре өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә билгеләнә.».

1.2. 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.0 пункт өстәргә:

«3.0. Гомуми билгеләр белән берләштерелгән аерым категория мөрәҗәгать итүчеләргә әлеге хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган, шул исәптән аны алу өчен мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, 2.15 пункты белән һәм әлеге бүлек белән билгеләнгән.».